СОВЕТ СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**27 март 2023 ел** Болгар ш. **№ 28-11**

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану һәм «Санлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында белешмәләр бирү хакында һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 09 сентябрендәге 10-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлешенә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, ТР Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИИТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

1.1. 2016 елның 30 мартындагы 6-7 номерлы «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында»;

1.2. 2022 елның 30 маенда № 20-4 «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Татарстан Республикасы Спас муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, ТР Спас муниципаль районы Советының

2016 елның 30 мартындагы 6-7 номерлы карары белән расланган (2021 елның 09 сентябрендәге 10-1 номерлы үзгәрешләр белән)».

2. «Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2021 елның 09 сентябрендәге 10-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1 пунктта «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы, «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче гражданнар» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2. 2 нче пунктны төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Спас муниципаль районы башлыгы урынбасары С.И. Тюнев